РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422057, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы,
19а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail:Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.07.2019

КАРАР
№ 18

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру уздыруны билгеләү һәм уздыру турында нигезләмәне раслау турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ Федераль законына, 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” №45-ЗРТ Татарстан Республикасы законына, Тимершык авыл җирлеге Уставына туры китереп, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә гражданнарның җирле үзидарәне башкару хокукларын гамәлгә ашыру, һәм шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Тимершык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халык фикерен белү һәм исәпкә алу максатыннан Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру уздыруны билгеләү һәм уздыру турында нигезләмәне расларга (кушымта теркәлә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча бастырып чыгарырга.

Тимершык авыл җирлеге башлыгы: Хаҗ А.Х.Хаҗиев

Расланган:

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Тимершык авыл җирлеге
Советының 2019 елның 3
июлендә чыккан 18 номерлы
карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру уздыруны билгеләү һәм уздыру турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Гражданнардан сораштыру (алга таба-сораштыру) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге халкының турыдан-туры ихтыяр белдерүенең бер формасы булып тора.

Сораштыру юлы белән гражданнарның җирле үзидарәне башкару хокукы гамәлгә ашырыла.

1.2. Сораштыру – җирле әһәмияттәге сорауларны чишкәндә һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары һәм органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә яки Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикерен ачыклау ысулы булып күзаллана.

1.3. Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим итү характерында була.

2. Сораштыру уздыру принциплары.

2.1. Сораштыру уздыруда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә яшәүче, сайлау хокукына ия гражданнар катнашырга хокуклы.

2.2. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә яшәүчеләр сораштыруда тигез нигезләрдә катнаша. Һәр катнашучы бер тавыш хокукына ия һәм сораштыруда турыдан-туры катнаша.

2.3. Гражданнарның сораштыруда катнашуына аларның җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи торышына, диненә, иманына, иҗтимагый берләшмәләрдә торуына бәйле нинди дә булса туры яки кыек чикләүләр рөхсәт ителми.

2.4. Сораштыруда катнашу ирекле һәм ихтыяри. Сораштыру барышында беркем дә үз фикерен һәм карашын белдерүгә яки аннан баш тартуга мәҗбүр ителә алмый.

2.5. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары халыкның сораштыруда катнашу хокукын гамәлгә ашыруына булышырга бурычлы.

3. Сораштыруга куела торган сораулар.

3.1. Сораштыруга түбәндәге сораулар куелырга мөмкин:

- Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагылучы һәм Тимершык авыл җирлеге Уставы белән җирле әһәмияттәге сорауларга карый торган;

- региональ һәм регионара әһәмияттәге объектлар өчен муниципаль берәмлек җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында.

3.2 Сораштыруга куелучы сораулар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закончалыкларына, Тимершык авыл җирлеге уставына каршы килмәскә тиеш.

Сораштыруга куелучы сораулар аларны күптөрле аңлауга юл куелмаслык итеп формалаштырылырга тиеш.

4. Сораштыру төрләре.

4.1. Сораштыру яшерен, исемләп яки ачык тавыш бирү юлы белән уздырыла.

4.2. Яшерен тавыш бирү- сораштыру битләре белән сораштыру уздыру пунктларында бер көн дәвамында уздырыла.

4.3. Исемләп тавыш бирү- сораштыру битләре яки сораштыру исемлеге буенча сораштыру пунктларында, шулай ук сораштыру уздыру комиссиясе членнары тарафыннан сораштыру уздыруда катнашучыларның яшәү урыннарында бер яки берничә көн дәвамында уздырыла.

4.4. Сораштыру шулай ук ачык формада гражданнар җыелышларында да уздырыла ала.

5. Сораштыруны билгеләү тәртибе.

5.1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру уздыру түбәндәгеләрнең инициативасы белән уздырыла:

1) җирле әһәмияттәге сораулар буенча җирлек башлыгы яки җирлек Советы;

2) региональ һәм регионара әһәмияттәге объектлар өчен муниципаль берәмлек җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү буенча халык фикерен исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары;

5.2. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы инициативасы белән уздырылучы сораштыру, күрсәтелгән орган тарафыннан сораштыру уздыру билгеләү турында карар кабул ителеп билгеләнә.

Җирлек башлыгы инициативасы белән билгеләнүче сораштыру, җирлек Советына сораштыру уздыру турында үтенеч җибәрү белән билгеләнә.

Татартсан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән билгеләнүче сораштыру, әлеге орган тарафыннан Тимершык авыл җирлеге Советына сораштыру уздыру турында үтенеч җибәрү белән билгеләнә.

5.3. Сораштыру уздыру турында үтенечтә:

- сораштыру уздыруның мотивлары;

- сораштыруга куелучы сорауның (сорауларның) тәкъдим ителүче формулировкасы;

- сораштыру территориясе;

- сораштыруның фаразланган көне һәм аның төре күрсәтелә.

5.4. Сораштыруны билгеләү турында карар Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә.

5.5. Сораштыру билгеләү турында карар үтенеч кергәннән соң һәм аны уздыру көненнән 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Сораштыру билгеләү турында карар кабул ителгәнче Тимершык авыл җирлеге Советының сораштыру уздыруның инициаторы белән сораштыруга куелучы сорауны алдан килештерү (аныклау) мөмкин.

5.6. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы, сораштыруга куелучы сорауның(сорауларның) формулировкасы гамәлдәге закончалыкларга, әлеге нигезләмәгә каршы килгән очракта, сораштыру уздыруның инициаторына сораштуры уздыруны кире кага.

5.7. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының сораштыру уздыру билгеләү турында карарында:

1) сораштыру уздыруның көне һәм срогы;

2) сораштыру уздыруга тәкъдим ителүче сорауның(сорауларның) формулировкасы;

3) сораштыру уздыру методикасы;

4) сораштыру битенең формасы;

5) сораштыруда катнашучыларның минималь саны күрсәтелә.

5.8. Сораштыру уздыру билгеләү турында карар аны уздыруга кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Сораштыру уздыру буенча комиссия.

6.1. Гражданнардан сораштыруны әзерләүне һәм оештыруны сораштыру уздыру буенча комиссия (алга таба –Комиссия) башкара.

6.2. Комиссия Тимершык авыл җирлеге Советы тарафыннан, сораштыру уздыру территориясенә бәйле рәвештә, инициаторлар тәкъдимнәре нигезендә 3-15 кешедән билгеләнә.

6.3. Комиссия составына Тимершык авыл җирлеге Советы, башка җирле үзидарә вәкилләре, шулай ук сораштыру уздырылучы иҗтимагый территорияләр вәкилләре керә.

6.4. Комиссия, ул оешу турында карар кабул ителгәннән соң, 3 көннән дә соңга калмыйча чакырыла. Беренче утырышында Комиссия, ачык тавыш бирү юлы белән үз составыннан Комиссиянең рәисен, аның урынбасар(лар)ын һәм сәркатибен сайлый, сораштыру участокларын раслый, һәм шулай ук әгәр

сораштыру пунктларда уздырылса, шундый пунктларның санын һәм урнашу урынын раслый.

Комиссия утырышларын зарурлыктан чыгып аның рәисе чакыра. Комиссия утырышы аның члennarының яртысыннан күбесе катнашкан очракта хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучыларның күпчелек ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Комиссия гражданнардан сораштыру уздыру өчен кирәк булган кадәр эшче төркемнәр оештырырга хокуклы.

6.5. Сораштыру участоклары, Комиссиянең урнашу урыны һәм гражданнардан сораштыру уздыру пунктларының урнашу урыны сораштыру уздыруга 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

6.6. Сораштыру уздыру буенча комиссия:

- гражданнардан сораштыру уздырганда әлеге Нигезләмәнең үтәлешен оештыра;

- сораштыру уздыру пунктларын җиһазландыра;

- сораштыру битләрен һәм сораштыру исемлекләрен әзерләүне тәэмин итә;

- сораштыру уздырганда имзалар җыюны оештыра;

- Саба муниципаль районы Тимершык аыл җирлегендә яшәүчеләрнең сораштыруда катнашуын тәэмин итә;

- сораштыру уздырганда яшәүчеләрнең тавыш бирүен әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә оештыра;

- Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә;

- гражданнардан сораштыру нәтиҗәләрен билгели;

- гражданнардан сораштыру уздыру белән бәйле шикаятьләр һәм гаризаларны карый;

- әлеге Нигезләмә һәм гамәлдәге закончалыкларга туры китереп башка вәкаләтләрне башкара.

6.7. Комиссиянең вәкаләтләре Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы тарафыннан сораштыру нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң туктатыла.

6.8. Комиссия эшчәнлегенең материаль-техник, оештыру ягын тәэмин итү Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы аппараты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Сораштыру участоклары. Сораштыруда катнашучылар исемлекләре.

7.1. Сораштыру участогы- сораштыру буенча комиссия тарафыннан билгеләнгән, гражданнардан сораштыру уздырылучы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясе.

Сораштыру территориясе бердәм сораштыру участогын тәэмин итәргә мөмкин.

Сораштыру участокларының сораштыру уздыру вакытында тавыш бирү өчен махсус җиһазланган биналары булырга тиеш. Сораштыру вакытында участокларда тавыш бирүне, участокларга җибәрелгән, Комиссиянең бер члены җитәкчелек иткән комиссия членнары тәэмин итә.

7.2. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә муниципаль берәмлекнең тавыш бирү хокукына ия гражданнары кертелә. Исемлектә сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьлекләргә туган көне һәм ае да) һәм яшәү адресы күрсәтелә. Яшәүчене конкрет участокта сораштыру уздыру буенча исемлеккә кертү өчен нигез булып, аның шушы участокта урнашу факты тора. Яшәүче сораштыру уздыру буенча сораштырылучылар исемлегенә бары тик бер участокта гына кертелә. Сораштыруда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә һәм исемлекне төзегән комиссия рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана.

Сораштыруда катнашу хокукына ия яшәүчеләрне өстәмә исемлеккә кертү әлеге нигезләмәгә туры китереп, теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сораштыру уздыру көнендә дә рөхсәт ителә.

Сораштыруда катнашу хокукына ия яшәүчеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү, тавышларны санау башланганнан соң, тыела.

Сораштыруда катнашучылар исемлеге сораштыру уздыру көненә 3 көннән дә соңга калмыйча төзелә.

8. Сораштыру бите.

8.1. Сораштыру бите сораштыруга куелган сорау(лар)ның төгәл текстын һәм аңа тавыш бирүченең ихтыяр белдерүен “риза” яки “каршы” сүзләре вариантлары астына куелган буш шакмаклардан гыйбарәт.

Сораштыруга берничә сорау куелган булса, алар бер сораштыру битенә урнаштырыла, эзлекле номерлана һәм бер-берсеннән горизонталь сызыклар белән аерылып тора. Сораштыруга куелган норматив-хокукый акт проектының нинди дә булса статьясы яки пунктының альтернатив редакциясе шулай ук эзлекле номерлана.

Исемләп тавыш бирү өчен кулланылучы сораштыру битенең тавыш бирүче турында мәгълүматлар язу өчен буш урыны булырга тиеш.

Сораштыру бите аны тутыру тәртибе турында аңлатманы үз эченә ала. Битнең өске уң почмагында Комиссия рәисе һәм сәркатибе имзалары куела.

9. Сораштыру исемлеге.

9.1. Сораштыру исемлеге исемләп тавыш бирү вакытында кулланыла һәм графаларына сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме,

туган көне, яшәү урыны язылган таблицадан гыйбарәт. Бу графаларның уң ягында сораштыруга куелган сорау(лар)ның төгәл тексты астында “риза” яки “каршы” җаваплары вариантлары күрсәтелә һәм тавыш бирүдә катнашучыларга имза кую өчен урын калдырыла.

Сораштыруга берничә сорау куелган очракта, алар сораштыру исемлегендә эзлекле тәртиптә урнаштырыла.

9.2. Сораштыру исемлегенең һәр бите Комиссия рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана.

10. Сораштыру уздыру тәртибе.

10.1. Сораштыру Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының сораштыру уздыру билгеләү турында карары белән билгеләнгән көндә (яки көннәрдә) уздырыла.

10.2. Гражданнардан сораштыру уздыру сораштыру уздыру пунктларында җирле вакыт белән иртәнге сигездән кичке сигезгә кадәр уздырыла.

11. Сораштыру уздырганда яшерен тавыш бирү тәртибе.

11.1 Яшерен тавыш бирү -сораштыру уздыру пунктларында, яшерен тавыш бирү өчен махсус җайланган урыннар һәм тавыш бирү вакытына мөһерләнгән тартмалар булган очракта уздырыла.

11.2. Сораштыру бите тавыш бирүчегә сораштыруда катнашучылар исемелеге буенча Комиссия членнары тарафыннан бирелә. Сораштыру бите алган вакытта тавыш бирүче аның шәхесен билгеләүче һәм яшәү урынын раслаучы паспортын күрсәтә, сораштыруда катнашучылар исемлегендә үз фамилиясе турына имзасын куя. Исемлеккә паспорт мәгълүматларын тутыру таләп ителми.

11.3. Тавыш бирүче исемлеккә үзе кул куя алмаган очракта, ул комиссия членнарыннан тыш башка кешенең ярдәменнән файдаланырга мөмкин.

Сораштыруда катнашучыга ярдәм күрсәткән зат, исемлекнең “сораштыру битен алу турында катнашучының имзасы” графасына, үзенең фамилиясен күрсәтеп кул куя.

11.4. Сораштыру бите тавыш бирүче тарафыннан махсус җиһазланган урында (кабина яки бүлмә), башка затлар булмаган җирдә тутырыла һәм тавыш бирер өчен куелган тартмага салына.

Тавыш биргән вакытта катнашучы үз ихтыярына туры китереп, “риза” яки “каршы” сүзләре астындагы шакмакка теләсә нинди тамга куя.

Комиссия членнары сораштыруның яшеренлеген тәэмин итә.

Тавыш бирүче сораштыру битен тутырганда хата җибәрдем дип исәпләгән очракта, ул Комиссия членына аңа бозылганы урынына яңа сораштыру бите бирүен сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Комиссия члены тавыш бирүчегә, катнашучылар исемлегендә аның фамилиясе каршына туры килә торган тамга куеп, яңа сораштыру бите бирә. Бозылган сораштыру бите яраксызландырыла, бу турыда Комиссия членнары тарафыннан акт төзелә.

Тутырылган сораштыру битләре тавыш бирүче тарафыннан, Комиссия членнарының күз уңында урнаштырылган тартмага төшерелә.

Тартмалар саны Комиссия тарафыннан тәгаенләнә. Тавыш бирүне күчерелеп йөртелә торган тартмалар белән уздыруны Комиссия мөстәкыйль хәл итә.

11.5. Әгәр комиссия члены сораштыру серен боза яки тавыш бирүченең ихтыярына басым ясарга маташа икән, ул кичекмәстән аның эшендә катнашудан читләштерелә. Читләштерү турында карар әлеге участоктагы эшне җитәкләүче комиссия члены тарафыннан, туры килә торган беркетмә төзеп һәм барлык комиссия членнары тарафыннан имзаланып, кабул ителә.

12. Сораштыру уздырганда исемләп тавыш бирү уздыру тәртибе.

12.1. Исемләп тавыш бирү- сораштыру уздыру пунктларында да, гражданнарның яшәү урыннарында да уздырылырга мөмкин.

12.2. Исемләп тавыш бирү- сораштыру битләре белән дә, сораштыру исемлеге белән дә уздырылырга мөмкин.

12.3. Сораштыру исемлеге буенча исемләп тавыш биргәндә, тавыш бирүче шәхесен һәм тору урынын раслаучы паспорт яки башка документ күрсәтеп, сораштыру исемлегендә үзенең фамилиясе каршына аның ихтыярын белдерүче теләсә нинди тамга куя һәм имзалый.

12.4. Сораштыру битләре буенча исемләп тавыш биргәндә, тавыш бирүче сораштыру битенә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, адресын яза, “риза” яки “каршы” сүзләре астында шакмакка үз ихтыярына туры китереп теләсә нинди тамга куя һәм шунда ук имзасын куя.

Тавыш бирүченең үтенече буенча, сораштыру битенә катнашучы турында мәгълүматны Комиссия члены тутырырга мөмкин, ләкин туры килә торган шакмакка тамганы һәм имзасын тавыш бирүче үзе куя.

12.5. Сораштыру уздыру барышында һәр көн азагында тутырылган сораштыру битләре, сораштыру уздыручылар тарафыннан, Комиссиягә тапшырыла.

12.6. Сораштыру битләре буенча тавыш бирү мәгълүматлары Комиссия членнары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләрен билгеләүче төп документ булып торучы сораштыру исемлегенә күчерелә.

13. Сораштыру үткәргәндә ачык тавыш бирү үткәрү тәртибе

13.1. Комиссия, сораштыруда катнашучы кешеләр саны 1000 кешедән артмаса, сораштыруда катнашкан сорау (мәсьәләләр) буенча тавыш бирү үткәрү өчен сораштыруда катнашучылар җыелышын үткәрергә хокуклы. Җыелышта катнашучыларны теркәү сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча үткәрелә. Җыелышны комиссия вәкилләре өч кешедән дә ким булмаган санда ачалар һәм алып баралар. Җыелышта кызыксынучы якларга сораштыруда куелган мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча сорау бирү рөхсәт ителә, сорауларына җавап бирелә, әмма фикер алышулар үткәрелми.

13.2. Җыелышта тавыш бирү һәр мәсьәлә буенча аерым «Өчен» һәм аерым «Каршы» үткәрелә. Тавыш бирүдә исемлеккә кертелгән һәм җыелышта теркәлгән

сораштыруда катнашучылар гына катнаша. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул җыелышта катнашучы барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

13.3. Сораштыруда исемлеккә кертелгән катнашучылар саны халык санының 25 процентыннан артса, җыелыш тулы хокуклы дип санала.

14. Сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү

14.1. Сораштыру үткәргәннән соң, Комиссия сораштыру нәтиҗәләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен исәпли һәм түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә торган сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә белән үзенең карарын рәсмиләштерә:

- беркетмә төзү датасы;
- сораштыру үткәрү вакыты: башлану һәм тәмамлану вакыты;
- сораштыру үткәрү буенча участок адресы;
- сораштыру территориясе (әгәр сораштыру җирлек территориясенең бер өлешендә үткәрелгән булса, торак пунктларның, урамнарның, йортларның номерларының исемнәре һичшиксез күрсәтелә);
- сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорау (сораулар) төзелеше ;
- сораштыруда катнашу өчен исемлеккә кертелгән гражданнарның гомуми саны;
- сораштыруда катнашкан гражданнар саны;
- сораштыруны узган яисә хәл ителмәгән дип тану ;
- сораштыру дөрес яки дөрес түгел дип тану;
- сораштыру исемлегендәге язмалар санын дөрес түгел дип яки сораштыру кәгазьләренең санын дөрес түгел дип тану;
- сораштыруга чыгарылган сорауга җавап биргәндә «Өчен» дип бирелгән тавыш саны;
- сораштыруга чыгарылган сорауга җавап биргәндә «Каршы» дип бирелгән тавыш саны;
- сораштыру нәтиҗәләре (мәсьәлә хупланган дип санала, әгәр тавыш бирүдә катнашучыларның яртысыннан күбе сорауга «Өчен»дип җавап бирсә).

14.2. Әгәр сораштыру берничә мәсьәлә буенча үткәрелгән булса, тавышларны санау һәм һәр мәсьәлә буенча беркетмә аерым төзелә.

14.3. Сораштыру кәгазендә язу дөрес түгел дип таныла, әгәр:

- сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес итеп билгеләү мөмкин булмаса ;
- язуда сайлаучы турында мәгълүматлар яки аның имзасы булмаса;
- кабатланган язмалар булса.

Сораштыру кәгазьләре гамәлдә түгел дип таныла:

- билгеләнмәгән үрнәктә булса,
- комиссия әгъзаларының тамгалары булмаса,
- алар буенча сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес итеп билгеләп булмаса.

14.4. Комиссия сораштыруны булмаган дип саный, әгәр сараштыруда катнашкан халык саны Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән минималь саннан ким булса.

14.5. Комиссия сораштыру нәтиҗәләрен дөрес түгел дип саный:

- әгәр сораштыру уздырган вакытта җибәрелгән хокук бозулар гражданнарның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөрес итеп билгеләргә мөмкинлек бирми икән;

- әгәр сораштыру исемлегендәге дөрес дип танылган язма саны сораштыруда катнашкан гражданнар санының 80%нан ким булса;

- әгәр сораштыру кәгазе саны сораштыруда катнашкан гражданнар санының 80%нан ким булса.

14.6. Сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә 2 нөсхәдә төзелә һәм комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәгә кул куйган вакытта комиссиянең кайбер әгъзалары булмаган очракта, беркетмәдә бу хакта, аларның юклыгы сәбәпләрен күрсәтеп, язып куела.

Комиссия әгъзасы беркетмә белән тулысынча яки аның аерым нигезләмәләре белән килешмәсә, беркетмәгә кушып бирелә торган аерым фикерне язмача язарга хокуклы, бу хакта беркетмәдә тиешле язма языла. Беркетмә дөрес дип санала, әгәр Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән комиссия әгъзалары саныннан күпчелек имза белән имзаланса.

Беркетмәгә кул кую көне комиссия әгъзалары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү көне булып тора.

14.7. Беркетмәнең бер нөсхәсе Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советына сораштыру кәгазьләре яки сораштыру исемлекләре белән бергә җибәрелә, беркетмәнең икенче нөсхәсе сораштыру үткәрү инициаторына җибәрелә.

Беркетмәнең бер нөсхәсенә комиссиягә кергән язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Шикаятьләрнең, гаризаларның һәм алар буенча кабул ителгән карарларның расланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлә.

Бер нөсхәнең күчермәләре массакүләм мәгълүмат чараларына, җирле иҗтимагый берләшмәләргә һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына тәкъдим итәлергә мөмкин.

14.8. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге комиссиясе һәм Советы сораштыру үткәрү буенча документларның сакланышын һәм тутырылган сораштыру кәгазьләренең кагылгысызлыгын тәэмин итә.

## 15. Сораштыру нәтиҗәләре

15.1. Сораштыру нәтиҗәләре аны үткәргәннән соң бер ай вакыт эчендә бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

15.2. Сораштыру барышында ачыкланган халык фикере тәкъдим итү сыйфатына ия. Сораштыру нәтиҗәләре җирле үзидарә органнары һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә мәҗбүри рәвештә каралырга һәм исәпкә алынырга тиеш.

15.3. Сораштыру нәтиҗәләренә каршы килә торган карарлар кабул ителгән очракта, вәкаләтләр һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) юлы белән мондый карар кабул итүнең сәбәпләрен халыкка җиткерергә тиеш.

## 16. Сораштыру материалларын саклау

16.1. Сораштыру материаллары Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советында Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы депутатларының вәкаләтләре тәмамлану вакытыына кадәр саклана, аннары муниципаль архивка җибәрелә.

16.2. Күрсәтелгән материалларны саклау срогы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, әмма 1 елдан да ким булырга тиеш түгел.

## 17. Сораштыру үткәрүне финанс яктан тәэмин итү

17.1. Гражданнар арасында сораштыру әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чараларны финанслау башкарыла:

- җирле бюджет хисабына – сораштыруны җирле үзидарә органнары инициативасы буенча үткәргәндә;
- Татарстан Республикасы бюджеты хисабына – сораштыруны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча үткәргәндә.

## 18. Сораштыруда катнашу хокукларын бозган өчен җаваплылык

18.1. Россия Федерация гражданин көч кулланып, сатып алып, янап, ялган документлар белән яки башка төрле гамәлләр белән ирекле рәвештә сораштыруда катнашырга, яисә комиссиянең эшенә яки әгъзаләренә каршылык күрсәткән затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылыкка тартылалар.